# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"17" ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, 2021 елның 16 нобрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 402 (дүрт йөз ике) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 223 (ике йөз егерме өч) кеше, бу 56,14 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 223 (ике йөз егерме өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты

территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү)" мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнебересинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1021606155405
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1610000476